ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР
дуртенче чакырышның утыз тугызынчы утырышы

21 май 2024 ел **№129** **Иске Җөри авылы**

Иске Җөри авыл җирлеге Советының 2023 елның 18 августындагы 95 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлеге Советының 10.06.2016 ел №31 карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Иске Җөри авыл җирлеге Советының 2023 елның 18 августындагы 95 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлеге Советының 2016 ел № 31 карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» карарына үзгәреш кертергә, преамбулада «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 декабрендәге 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Иске Җөри авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Мараков